ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**27.11.2023**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**3769**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 - 2023 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау буенча муниципаль программаны раслау турында» 2020 елның 3 декабрендәге 2315 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 6.1 пунктының 1 өлеше, 2006 елның 6 мартындагы «Терроризмга каршы тору турында» 35-ФЗ номерлы, «Экстремистик эшчәнлеккә каршы тору турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының «Терроризмга каршы көрәш чаралары турында» 2006 елның 15 февралендәге 116 номерлы Указы һәм Зеленодольск муниципаль районында террорчылыкка һәм экстремизмга каршы тору системасын камилләштерү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 - 2023 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау буенча муниципаль программаны раслау турында» 2020 елның 3 декабрендәге 2315 номерлы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар исемендә «2021-2023» саннарын «2021-2024» саннарына алмаштырырга;

1.2. Карарның 1п. «2021-2023» саннарын «2021-2024» саннарына алмаштырырга;

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 - 2023 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау буенча муниципаль программаны раслау турында» 2020 елның 3 декабрендәге 2315 номерлы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

2.1. кушымта исемендә «2021-2023» саннарын «2021-2024» саннарына алмаштырырга;

2.2. Программа паспортында:

- «Программа исеме» юлында «2021 - 2023» саннарын «2021 - 2024» саннарына алмаштырырга;

- «Программаны гамәлгә ашыру сроклары» юлында «2021 - 2023» саннарын «2021 - 2024» саннарына алмаштырырга;

- «Программаны финанслау (күләме һәм чыганаклары)» юлында таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
| Муниципаль бюджет (мең сум) | 92,5 | 345 | 185 | 315 | 937,5 |
| Республика бюджеты (мең сум) | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Федераль бюджет (мең сум) | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Башка чыганаклар (мең сум) | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Барлыгы (мең сум) | 92,5 | 345 | 185 | 315 | 937,5 |

2.3. «Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү» IV бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

Программаны тормышка ашыру чорында барлыгы-937,5 мең сум, шул исәптән программаны гамәлгә ашыру еллары буенча:

2021 ел - 92,5 мең сум;
2022 ел - 345 мең сум;
2023 ел - 185 мең сум;
2024 ел - 315 мең сум.

Әлеге программаны тормышка ашыру белән бәйле чараларны тиешле финанс елына финанслау Зеленодольск муниципаль районы бюджетында расланган ассигнованиеләр чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Программаны тормышка ашыруга тотылган акчаларның күләме район бюджеты мөмкинлекләреннән, инфляция процессларыннан һәм Зеленодольск муниципаль районы территориясендәге икътисади хәлләрдән чыгып төгәлләштерелергә һәм төзәтелергә мөмкин.

2.4. «Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау» программасының VII бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ОГРН 1061673000993 КПП 164801001

## VII. ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЛАРЫ, БУРЫЧЛАРЫ, НӘТИҖӘЛӘРЕН БӘЯЛӘҮ ИНДИКАТОРЛАРЫ ҺӘМ ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ БУЕНЧА ФИНАНСЛАУ

| Максатның атамасы | Бурычның атамасы | Ярдәмче программаның атамасы | Төп чаралар исемнәре | Башкаручылар | Төп чараларны гамәлгә ашыру сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | | Зеленодольск муниципаль районы бюджеты хисабына финанслау, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | 2020 ел (база) | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| Максаты: Зеленодольск муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнарның экстремизмга һәм террорчылыкка каршы тору, аларның чагылышларын профилактикалау һәм кисәтү | 1 нче бурыч. Террорчылык идеологиясе йогынтысына дучар булган затлар белән, шулай ук аның йогынтысы астына эләккән затлар белән профилактик эш | Ярдәмче программа эшләнмәгән | 1.1. «Аерым игътибар» (риск) категориясендәге затлар белән эшләү буенча муниципаль ведомствоара эшче төркем эшен тәэмин итәргә | ЗМР БК, ҖҮО башлыклары , ЗР буенча ЭЭМ, Зеленодольскида ФКХ ТР буенча идарәсе | 2021-2024 еллар | Эшче төркемнәр утырышлары саны | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | * | * | * | * |
| | | | 1.2. «Аерым игътибар» (риск) категориясендәге затлар белән адреслы профилактик чараларда катнашу өчен коммерцияле булмаган (шул исәптән дини) оешмаларны һәм иҗтимагый активларны стимуллаштыру | ЗМР БК, ҖҮО башлыклары | 2021-2024 еллар | Иҗтимагый активистларны җәлеп итеп, профилактик эш | 40 | 50 | 60 | 70 | 80 | 0 | 30 | 0 | 30 |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| нигезендә, законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау дәрәҗәсен арттыру; | алып бару өчен шартлар булдыру | | чараларын гамәлгә ашыру | | | белән колачланган «аерым игътибар» (риск) категориясендәге затлар өлеше | | | | | | | | | |
| | | | 1.3. «Аерым игътибар» (риск) категориясендәге кешеләр белән эшләүдә, хәлне диагностикалауда, психологик һәм психотерапевтик ярдәм күрсәтүдә катнашкан вазыйфаи затларны һәм җәмәгать активистларын әзерләү өчен квалификацияле белгечләр җәлеп итүне тәэмин итәргә. | ЗМР БК | 2021-2024 еллар | Белемле, квалификацияле белгечләр саны | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 0 | 30 | 0 | 30 |
| | | | 1.4. Яшьләр тармагы белгечләренең, спорт оешмаларының, яшьләр җәмәгать активистларының «аерым игътибар» (риск)категориясендәге кешеләрнең | ЗМР БК, ЗМР ЯЭБ ЗМР БК СБ | 2021-2024 еллар | Күрсәтелгән хезмәт төрләре белән җәлеп ителгә | 10 | 15 | 20 | 25 | 30 | * | * | * | * |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | социализацияләү характерына ярдәм итүнең өзлексез чараларын гамәлгә ашыруда актив катнашуын тәэмин итәргә | | | н «аерым игътибар» (риск) категориясендәге затлар өлеше | | | | | | | | | |
| | | | 1.5. Функциональ регламент белән беркетелгән белем бирү оешмаларының вазыйфаи затларының «аерым игътибар» (риск) категориясендәге затлар белән адреслы эш алып баруда актив катнашуын тәэмин итәргә | ЗМР БК, ЗМР БК МИ | 2021-2024 еллар | «Аерым игътибар» (риск) категориясендәге затлар (яисә аларның балалары) укый торган уку сыйныфлары белән төркемле коррекциялау | 70 | 80 | 85 | 90 | 95 | * | * | * | * |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | чаралары (тренинглар, семинарлар) өлеше | | | | | | | | |
| | | | 1.6. Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасының барлык субъектлары белгечләренең «аерым игътибар» (риск) категориясе гаиләләре белән профилактик чараларны, шул исәптән торгызу медиациясе техникасын кулланып, актив катнашуын тәэмин итәргә | ЗМР БК, ЗМР АТК, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы субъектлары | 2021-2024 еллар | | - | +10 % | +10 % | +10 % | +10 % | * | * | * | * |
| | | | 1.7. Адреслы профилактик эштә катнашучы белгечләрнең һөнәри осталык буенча тармакара семинарлар үткәрергә | ЗМР БК, ЗМР АТК | 2021-2024 еллар | Семинарлар саны | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | * | * | * | * |
| | | | 1.8. Яшьләр арасында һәм мәгариф өлкәсендә мәгариф, яшьләр, | ЗМР БК, ЗМР БК МИ, ЗМР | 2021-2024 еллар | Күрсәтелгән тармак | | +10 % | +10 % | +10 % | +10 % | * | * | * | * |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | медицина, социаль яклау тармагында социаль педагогларны, психиатрларны җәлеп итү өчен һөнәри юнәлеш бирү эшен алып барырга, тиешле белем алу һәм муниципаль берәмлектә белгечлек буенча эшкә урнашу өчен мәгълүмати ярдәм күрсәтергә | БК ЯЭБ, ЗМР БК СБ, ЗМР ОСЗ МТЗиСЗ, «Зеленодольск РҮХ» ДАСУ | | лардагы белгечләрне комплектлау проценты | | | | | | | | | |
| | | | 1.9. Террорчылык идеологиясен ныклы кабул итмәүне формалаштыруга һәм массакүләм мәгълүмат чараларында, социаль челтәрләрдә, иҗтимагый чараларда Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрен тәрбияләүгә юнәлдерелгән чыгышларга аерым игътибар (риск) категориясендәге кешеләрне җәлеп итү буенча эш алып барырга | ЗМР БК, ЗР буенча ЭЭМ, Зеленодольск ТР буенча РФ ФКХ «Татмедиа» ААҖ филиалы | 2021-2024 еллар | Мондый аңлатмалар белән чыгыш ясаган «аерым игътибар» (риск) категориясендәге затлар өлеше | 5 | 5 | 10 | 10 | 10 | 0 | 20 | 0 | 20 |
| | | | 1.10. Системалы хезмәт һәм уку процессына җәлеп ителмәгән | ЗМР БК,ЗМР ЯЭБ, | 2021-2024 еллар | Максатчан аудито | | +10 % | +10 % | +10 % | +10 % | * | * | * | * |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | яшьләрне, шулай ук формаль булмаган яшьләр оешмалары вәкилләрен, иҗтимагый әһәмиятле социаль проектларны һәм программаларны тормышка ашыруга җәлеп итү буенча чаралар оештырырга һәм үткәрергә | | | риянең гомуми санына җәлеп ителгән яшьләр өлеше | | | | | | | | | |
| | | | 1.11. Интернет» челтәрендәге деструктив берләшмәләрдә муниципаль берәмлек халкының активлыгына мониторинг үткәрүне тәэмин итәргә (катнашучыларны матди кызыксындыру) | ЗМР БК, ЗМР ЯЭБ ЗМР БК МИ, Форпост МБУ | 2021-2024 еллар | Мониторинг нәтиҗәләре буенча мәгълүмати белешмәләр саны | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 | 80 | 50 | 50 | 50 |
| | | | 1.12. Муниципаль берәмлектә таратыла торган материалларны экстремизм билгеләре булу-булмауга даими мониторинг оештырырга һәм тикшеренүләр үткәрергә | ЗМР БК | 2021-2024 еллар | Үткәрелгән тикшеренүләр саны | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | * | * | * | * |
| | | | 1.13. Дини оешмалар җитәкчелеге белән берлектә Татарстан Республикасы өчен традицион ислам | ЗМР БК | 2021-2024 еллар | | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | * | * | * | * |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | формаларын тотучы рухи лидерларны әзерләү өчен Россиянең әйдәп баручы теологик уку йортларына (Болгар ислам академиясе) кандидатларны сайлап алу һәм җибәрү процедурасын оештырырга | | | | | | | | | | | | |
| | 2 нче бурыч. Зеленодольск муниципаль районы халкында терроризмга каршы аң формалаштыру | | 2.1. Мәгълүмати-пропаганда төркеме эшчәнлеген тәэмин итү (катнашучыларны матди кызыксындыру) | ЗМР БК, ҖҮО башлыклары, ТР буенча ЭЭМ бүлеге, Зеленодольск шәһәр прокуратурасы, дини, иҗтимагый, мәгариф һәм фәнни оешмалар | 2021-2024 еллар | Эшче төркемнәр утырышлары саны | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | * | * | * | * |
| | | | 2.2. Терроризмга каршы юнәлештәге күрсәтмә агитация продукциясен (стикерлар, брошюралар, | ЗМР БК, ҖҮО башлыклары | 2021-2024 еллар | Җәмәгатьчелек игътибары | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 12,5 | 50 | 50 | 50 |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | плакатлар) эшләргә, әзерләргә һәм таратырга (урнаштырырга) | | | өчен урнаштырылган продукция берәмлекләре саны | | | | | | | | | |
| | | | 2.3. Халык белән мәгълүмати-аңлату эше өчен матди стимуллаштыруны күздә тотып квалификацияле пропор-пропагандистларны җәлеп итүне тәэмин итәргә | ЗМР БК, ҖҮО башлыклары | 2021-2024 еллар | Җәлеп ителгән лекторлар үткәргән лекцияләр/чыгышлар саны | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 0 | 60 | 30 | 30 |
| | | | 2.4. Халык белән мәгълүмати-аңлату эшләре алып бару өчен лектор-пропагандистларның муниципаль активын әзерләүне тәэмин итәргә | ЗМР БК, ҖҮО башлыклары | 2021-2024 еллар | Муниципаль берәмлек халкы арасыннан укытылган, квалификацияле лекторлар саны | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | * | * | * | * |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2.5. Терроризмга каршы көрәштә бердәмлек көненә багышланган иҗтимагый-сәяси, мәдәни һәм спорт чаралары үткәрү (3 сентябрь) | ЗМР БК, ЗМР БК МИ, ЗМР БК МИ, ЗМР ИК СБ, ЗМР БК ЯЭБ, «Татмедиа» ААҖ филиалы | 2021-2024 еллар | Чаралар саны | | | | | | 0 | 20 | 0 | 20 |
| | | | 2.6. "Экстремизмга-юк» ункөнлеген үткәрү (4-14 сентябрь) | ЗМР БК, ЗМР БК МИ, ЗМР БК МИ, ЗМР ИК СБ, ЗМР БК ЯЭБ, «Татмедиа» ААҖ филиалы | 2021-2024 еллар | Чаралар саны | | | | | | 0 | 30 | 0 | 30 |
| | | | 2.7. Уяулыкны саклау, терроризмны һәм экстремизмны профилактикалауда катнашу мәсьәләләре буенча муниципаль районда гражданнар җыеннарын үткәрү | ЗМР БК, ҖҮО башлыклары | 2021-2024 еллар | авыл җирлекләрендә җыеннар саны | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | * | * | * | * |
| | | | 2.8. Социаль челтәрләрнең муниципаль сегментында, район Интернет челтәренең башка мәгълүмати | ЗМР БК, «Татмедиа» ААҖ филиалы | 2021-2024 еллар | Урнаштырылган материаллар саны | | | | | | * | * | * | * |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ресурсларында террорчылыкка каршы эчтәлектәге мәгълүматны, шул исәптән видеороликларны эшләүне (сайлап алуны) һәм урнаштыруны тәэмин итәргә | | | | | | | | | | | | |
| | | | 2.9. Массакүләм мәгълүмат чараларында терроризмга каршы тору эшендә гражданнарны бердәмләштерүгә юнәлдерелгән рәсми дини конфессияләр (православие, ислам) вәкилләренең тематик вәгазьләрен бастырып чыгаруны оештырырга | ЗМР БК, «Татмедиа» ААҖ филиалы, дини һәм иҗтимагый оешмалар (килешү буенча) | 2021-2024 еллар | Мәкаләләр саны | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | * | * | * | * |
| | | | 2.10. Авыл клубларында һәм мәдәният йортларында терроризмга һәм экстремизмга каршы юнәлештәге документаль һәм нәфис фильмнарны даими рәвештә күрсәтүне оештырырга, аннары аудитория белән фикер алышырга. | ЗМР БК, ЗМР БК МИ | 2021-2024 еллар | Күрсәтүләр саны | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 | * | * | * | * |
| | | | 2.11. Яшьләр арасында кейс чемпионатлар, | ЗМР БК,ЗМР | 2021-2024 | Чаралар | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 0 | 25 | 25 | 25 |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | квестлар, түгәрәк өстәлләр, очрашулар, фестивальләр, конкурслар, акцияләр оештырырга | ЯЭБ, | еллар | саны | | | | | | | | | |
| | | | 2.12. Терроризмга һәм экстремизмга каршы тору өлкәсендә иң яхшы проектка (иҗади эшкә) конкурс үткәрү | ЗМР БК,ЗМР ЯЭБ, | 2021-2024 еллар | Конкурска гаризалар саны | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 0 | 30 | 30 | 30 |
| | | | 2.13. Тематик түгәрәк өстәлләр, конференцияләр, конкурслар, ата-аналар җыелышлары, сыйныф сәгатьләре, акцияләр, коммуникатив күнекмәләрне үстерүгә, дуслык, милләтара һәм диниара татулык идеяләрен популярлаштыруга юнәлдерелгән тренинглар оештырырга | ЗМР БК, ЗМР БК МИ | 2021-2024 еллар | Чаралар саны | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | * | * | * | * |
| | | | 2.14. Үзара аңлашу, милләтара теләктәшлек, балаларның медиаиминлеге мәсьәләләрендә белем дәрәҗәсен арттыруга юнәлдерелгән «Ата-аналар өчен университет» форматы | ЗМР БК, ЗМР БК МИ | 2021-2024 еллар | Профилактик дәресләрдә катнашкан ата-аналар өлеше, гаиләл | 50 | 55 | 60 | 65 | 70 | * | * | * | * |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | кысаларында дәресләр үткәрүне оештырырга | | | әрнең гомуми өлеше ндә, % | | | | | | | | | |
| **Барлыгы 937,5 мең сум акча тотылган.** | | | | | | | | | | | | 92,5 | 345 | 185 | 315 |

Кулланылган кыскартмалар исемлеге:
ЗМР БК-Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты;
ЗМР ҖҮО башлыклары-Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары башлыклары;
ЗМР АТК – Зеленодольск муниципаль районында террорчылыкка каршы комиссия;
ЗР буенча ЭЭМ бүлеге-Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлеге;
Зеленодольск ш. ТР буенча РФ ФКХ - Татарстан Республикасы буенча РФ Федераль куркынычсызлык хезмәте идарәсенең Зеленодольск шәһәрендәге бүлеге;
ЗМР БК МИ - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе;
ЗМР БК МИ - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе;
ЗМР БК СБ - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлеге;
ЗМР БК ЯЭБ - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре бүлеге;
Форпост МБУ - "ФОРПОСТ" җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләренең Зеленодольск үзәге»;
ЗМР ОСЗ МТЗиСЗ - Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге

*Искәрмә: Финанслау күләме программага кертелгән предприятиеләрне һәм учреждениеләрне агымдагы финанслау хисабына каралган.

Зеленодольск муниципаль районында
террорчылыкка каршы комиссия секретаре А. В. Леухин